**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

05.07.2018 № 520

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында көндәшлекне үстерү Программасын раслау турында

"Россия Федерациясендә көндәшлекне үстерү буенча дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләре турында" 2017 елның 21 декабрендәге 618 нче номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә расланган 2018-2020 елларда Россия Федерациясендә көндәшлекне үстерүнең Милли планын үтәү йөзеннән

КАРАР БИРӘМ:

1. 2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында көндәшлекне үстерү Программасын расларга (кушымта).
2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.С. Әхмәтшин

Татарстан Республикасы Нурлат  муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 ел, 5 июль, 520 номерлы
карары белән расланды

# 2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында көндәшлекне үстерү ПРОГРАММАСЫ

Нурлат шәһәре
2018 ел

ЭЧТӘЛЕК

2018-2020 ЕЛЛАРГА НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА КӨНДӘШЛЕКНЕ ҮСТЕРҮ ПРОГРАММАСЫ ПАСПОРТЫ.............................................................3
КЕРЕШ.............................................................................................................4
1.НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА КӨНДӘШЛЕКНЕ ҮСТЕРҮ ПРОГРАММАСЫНЫҢ МАКСАТЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ.......................................4
2. РАЙОН ТОВАРЛАР ҺӘМ ХЕЗМӘТ БАЗАРЛАРЫНДА КӨНДӘШЛЕК МОХИТЕН АНАЛИЗЛАУ ҺӘМ БӘЯЛӘҮ...........................................................5
2.1. Мәктәпкәчә белем өлкәсендәге хезмәт базары.................................................5
2.2. Балалар ялы һәм сәламәтләндерүне оештыру өлкәсендә хезмәт базары................6
2.3. Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге хезмәт базары...................................7
2.4. Пассажирлар ташу өчен җир өсте транспорты өлкәсендәге хезмәт базары.....9
2.5. Ваклап сату базары.......................................................................................11
2.6. Ит, ит продуктлары һәм авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү базары..13
2.7. Мәдәният өлкәсендә хезмәт базары.................................................................17
2.8. Туризм өлкәсендә хезмәт базары....................................................................18

3.Көндәшлекне үстерү өлкәсендә беренчел чаралар..............................................19
4. Программаны гамәлгә ашыру тәртибе..............................................................22
5.Иҗтимагый-икътисадый нәтиҗәлелекне бәяләү
Программалар.................................................................................................23

2018-2020 елларга Нурлат муниципаль районында көндәшлекне үстерү Программасының Паспорты

| | |
|---|---|
| Программа исеме | 2020 елга кадәр Татарстан Республикасында көндәшлекне үстерү Программасы |
| Программаны эшләү турында карар кабул итү датасы (раслау турында дата, тиешле норматив актның исеме һәм номеры) | Программа "Россия Федерациясендә көндәшлекне үстерү буенча дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләре турында" 2017 елның 21 декабрендәге 618 нче номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә расланган 2018-2020 елларда Россия Федерациясендә көндәшлекне үстерүнең Милли планын үтәү йөзеннән эшләнде |
| Программаның координаторы | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны эшләүчеләр | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге |
| Программаның максат һәм бурычлары | Программаның максаты: районның товарлар һәм хезмәт базарында көндәшлек мохите булдыру һәм бизнес алып бару өчен уңайлы шартлар тудыру, товарлар ассортиментын киңәйтү, эшләр, хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын арттыру һәм бәяләрне төшерү исәбенә кулланучылар ихтыяҗы артуын тәэмин итү. Куелган максатка ирешү түбәндәге бурычларны хәл итүгә кайтып кала:<br>- товарлар һәм хезмәтләр базарына "керү"нең нигезсез административ һәм икътисади каршылыкларын бетерү;<br>- бизнесны алып бару, компанияләр һәм базарлар үстерү, район халкының ихтыяҗларын тулырак канәгатьләндерү өчен уңай базар мохитен формалаштыру;<br>- икътисади җайга салуның инструментларын куллануны, шул исәптән муниципаль сатып алуларны планлаштыруны камилләштерү;<br>- көндәшлек дәрәҗәсенә тәэсир итүче хуҗалык итүче субъектлар, җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең мәгълүмати ачыклыгын булдыру, кулланучыларның икътисади мәнфәгатьләренең хокукларын яклау. |
| Гамәлгә куелу вакыты | 2018-2020 еллар |
| Финанслауның күләме һәм чыганаклары | Каралмаган |
| Программаны гамәлгә ашырудан көтелгән нәтиҗәләр | Программаны үтәүнең төп нәтиҗәсе булып районның барлык товар базарларында конкуренциягә сәләтле продукция җитештерү һәм халыкка сыйфатлы хезмәт күрсәтү торырга тиеш |

# Кереш

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы иҗтимагый-икътисади үсеш стратегиясенең концепциясе тарафыннан 2030 елга кадәр киләчәк икътисадын формалаштыру бурычы куелган. Эш урыннары булдыру мөмкинлекләре һәм икътисадның ныклы үсеше нигезендә бизнес алып бару ягыннан Нурлат муниципаль районы бизнес һәм шәхес үсеше өчен бигрәк тә җәлеп итүчән булырга тиеш. Агымдагы вәзгыять һәм планлаштырыла торган максатчан күрсәткечләрне чагыштырудан чыгып билгеләнә торган стратегик аерымлыкларны, бүген, моңа кадәр беркайчан да булмаганча бәяләү һәм узып китү мөһим. Көндәшлек өлкәсендәге проблемаларны системалы хәл итмичә, куелган бурычларны хәл итү мөмкин түгел. Нәкъ менә бу өлкәдәге сәясәт көндәшлеккә сәләтлелекне һәм икътисади нәтиҗәлелекне билгеләүче төп фактор булып, һәм, ахыр чиктә, халыкның яшәү сыйфатын күтәрүче булып тора.

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында көндәшлекне үстерү Программасы (алга таба – Программа) "Россия Федерациясендә көндәшлекне үстерү буенча дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләре турында " 2017 елның 21 декабрендәге 618 нче номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә расланган 2018-2020 елларда Россия Федерациясендә көндәшлекне үстерүнең Милли планын үтәү йөзеннән эшләнде.

## 1. Нурлат муниципаль районында көндәшлекне үстерү Программасының максаты һәм бурычлары

Программаның максаты: районның товарлар һәм хезмәт базарында көндәшлек мохите булдыру һәм бизнес алып бару өчен уңайлы шартлар тудыру, товарлар ассортиментын киңәйтү, эшләр, хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын арттыру һәм бәяләрне төшерү исәбенә кулланучылар ихтыяҗы артуын тәэмин итү. Куелган максатка ирешү түбәндәге бурычларны хәл итүгә кайтып кала:

- товарлар һәм хезмәтләр базарына "керү"нең нигезсез административ һәм икътисади каршылыкларын бетерү;
- бизнесны алып бару, компанияләр һәм базарлар үстерү, район халкының ихтыяҗларын тулырак канәгатьләндерү өчен уңай базар мохитен формалаштыру;
- икътисади җайга салуның инструментларын куллануны, шул исәптән муниципаль сатып алуларны планлаштыруны камилләштерү;
- көндәшлек дәрәҗәсенә тәэсир итүче хуҗалык итүче субъектлар, җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең мәгълүмати ачыклыгын булдыру, кулланучыларның икътисади мәнфәгатьләренең хокукларын яклау.

Әлеге Программа 2020 елга кадәр Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында көндәшлекне үстерүнең төп өстенлекле юнәлешләрен билгели.

## 2. Район товарлар һәм хезмәт базарында көндәшлек мохитен анализлау һәм бәяләү

### 2.1. Мәктәпкәчә белем өлкәсендәге хезмәт базары

Мәктәпкәчә белем учреждениесенең төп максатларынның берсе булып балаларның тормышларын саклау һәм физик һәм психик сәламәтлеген ныгыту тора.

Нурлат муниципаль районы мәктәпкәчә белем системасы балаларның үсеш һәм сәламәтлек үзенчәлекләрен, ата-аналар йөкләвен исәпкә алып булдырылган күпфункцияле мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре челтәреннән гыйбарәт.

Нурлат муниципаль районында 29 балалар бакчасы һәм гомумибелем учреждениеләрендә 11 мәктәпкәчә белем төркеме эшли. 2018 елның 1 сентябренә булган мәгълүматлар буенча, 1 яшьтән 7 яшькә кадәрге балалар саны 4292не тәшкил итә. Мәктәпкәчә белем бирүнең күләме 65,5% тиң.

Мәктәпкәчә белем оешмаларында булдырылган 2790 урында 2752 бала тәрбияләнә. Район күләмендә татар телендә белем һәм тәрбия бирүче 9 балалар бакчасы (55%), чуаш телендә – 2 балалар бакчасы (10%) эшчәнлек алып бара.

Федераль дәүләт стандартлары таләпләрен исәпкә алып, мәктәпкәчә белем өлкәсендә төп белем бирү программаларын яңарту буенча эш алып барылды. Мәктәпкәчә учреждениеләрнең төрле дәрәҗәдәге конкурсларда катнашу сыйфаты да, саны да арта.

Мәктәпкәчә белем оешмаларында барлык балалар рус һәм татар телләрендә белем ала. 15 нче “Алсу” балалар бакчасы базасында балаларны ике дәүләт теленә өйрәтүдә нәтиҗәле инновацион технологияләр кертү буенча база мәйданчыгы булдырылды.

Мәктәпкәчә белем системасында проблема булып авыл җирлегендә урнашкан балалар бакчаларында балалар санының аз булуы кала бирә.

Район күләмендә алганда, мәктәпкәчә белем бирү күләме 85,6% тәшкил итсә, авыл җирлегендә ул 13,4% дәрәҗәсендә.

Максат: мәктәпкәчә белемнең сыйфатын арттыру, авыл җирлегендә яшәүче 3-7 яшьлек балаларга мәктәпкәчә тәрбия бирүнең күләмен 100% ка җиткерү.

Бурыч: авылда урнашкан балалар бакчаларына йөрүче балалар санын арттыру, мәктәпкәчә белем өлкәсендә хезмәт күрсәтүнең сыйфатын үстерү.

Чаралар:

| № | Үткәрелүче чаралар исеме | Чараны уздыручылар һәм катнашучылар | Гамәлгә кую вакыты | Максатчан күрсәткечләр |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Методик эшне оештыру өчен, аз комплектлы балалар бакчаларын база булып саналган мәктәпкәчә белем оешмаларына беркетү | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты, мәгариф бүлеге | 2018-2020 еллар | Халыкның мәктәпкәчә белем хезмәтеннән канәгать булуын арттыру, авыл балалар бакчаларында балалар санын арттыру |

## 2.2. Балалар ялы һәм сәламәтләндерүне оештыру өлкәсендә хезмәт базары

Нурлат муниципаль районы территориясендә балалар ялын һәм сәламәтләндерүне оештыру Россия Федерациясе дәрәҗәсендә дә, сәламәтләндерү оешмасында булганда төрле категориядәге балаларга ял чорында хокукларын тормышка ашыруны, куркынычсызлыкны тәэмин итүче Татарстан Республикасы дәрәҗәсендә дә кабул ителгән норматив хокукый актлар белән билгеләнә. Балалар сәламәтләндерүгә булган ихтыяҗны тәэмин итәргә сәләтле лагерьлар санының тиешенчә булмавы балалар ялы һәм сәламәтләндерүне оештыру өлкәсендәге хезмәт базарында көндәшлекне үстерүне тоткарлаучы; шулай ук балалар ялы һәм сәламәтләндерүне оештыру буенча хезмәт күрсәтүгә яраклы СанПиН таләпләренә җавап бирүче биналарның юклыгы, әлеге өлкәдә белеме булган кадрларның җитәрлек күләмдә булмавы; балалар сәламәтләндерү лагерьларын төзү өчен матди чыганаклар җәлеп итүнең авырлыгы да төп фактор булып тора.

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында 31 лагерь эшли: 3 шәһәр яны лагере – “Чияле алан”, “Заречный”, “Лучезарный”, 2 палаткалы лагерь – “Ратный сбор”, “Патриот” (“Каһарман”), көндез эшләүче 23 мәктәп яны лагерьлары, 3 ял һәм хезмәт лагере. 2017 ел дәвамында лагерьларда 2210 бала ял итте.

Хәл ителәсе мәсьәлә: балалар һәм яшьләр ялын, сәламәтләндерүне оештыру өлкәсендә район халкының канәгатьлеген арттыру.

Максат: ял һәм сәламәтләндерү системасын үстерү, бу эшкә җәлеп ителгән оешмаларның материаль-техник базасын ныгыту.

Бурыч: балаларны ял, сәламәтләндерү һәм төрле шогыльләргә җәлеп итүнең күләмен арттыру.

Чаралар:

| № | Үткәрелүче чаралар исеме | Чараны уздыручылар һәм катнашучылар | Гамәлгә кую вакыты | Максатчан күрсәткечләр |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Ата-аналарның иҗтимагый дәрәҗәләренә һәм матди хәлләренең нинди булуына карамастан, балаларның ял һәм сәламәтләндерүгә булган хокукларын тәэмин итүдә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты белән хезмәттәшлек итү.<br>Район бюджетыннан балалар ялын оештыруга акча бүлеп бирү. | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты, яшьләр эшләре бүлеге, балансta балалар һәм яшьләр ялы биналары торган оешмалар | 2018-2020 еллар | Нурлат муниципаль районында яшәүче ял һәм сәламәтләндерү хокукыннан файдаланган 7 – 17 яшькә кадәрге балалар саны 2018 ел -2060, 2019 ел – 2070, 2020 ел – 2080. |

## 2.3. Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге хезмәт базары

Нурлат муниципаль районында хезмәт күрсәтү өлкәсендә иҗтимагый яктан иң әһәмиятле тармак булып торак-коммуналь хуҗалыгы санала. Төп коммуналь хезмәтләрне күрсәтүче булып 4 предприятиене атарга мөмкин: “Промочистка” ҖЧҖ, “Җылылык челтәре” ҖЧҖ, “Татэнергосбыт” ААҖ, “Нурлатгаз” ЭПУсы.

Шәһәрнең торак фондына 356 күпфатирлы йорт карый, алар белән идарә итү өчен 9 оешма җәлеп ителгән: “ТКХ ИК” МУП, “Уңайлы йорт ИК” ҖЧҖ, “Нурлат-Нефтьче» ҖЧҖ, “Коммунальник» ҖЧҖ, “Экодом ИК” ҖЧҖ, “Эталон”ҖЧҖ, “Торак Нурлат шәһәре” ҖЧҖ, “Престиж» ҖЧҖ, “Шәһәрчек” ҖЧҖ.

Көнкүреш калдыкларын чыгару хезмәтен “Мехуборка – Кама” ҖЧҖ башкара. Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә көндәшлекне үстерүгә комачаулаучы факторлар булып: җитештерүчәнлекнең зур чыгымнар соравы;

- капиталь төзелешнең кыйммәт булуы; инвестицион проектларның үзен-үзе аклау вакыты озак булу; тариф сәясәтенең тотрыксызлыгы һәм тарифларның ачык булмавы; финанс агымнарының тиешле дәрәҗәдә ачык булмавы;
- тариф сәясәтенең билгесезлеге аркасында инвестицияләрне югалту куркынычы; ризасызлык белдерү эшендә нәтиҗәле система булмау;
- кулланучыларның коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итүче оешмалар сайлау мөмкинлеге булмавы; идарәче компанияләрнең түбән профессионализмлы булуы.

Торак – коммуналь хуҗалыкның көндәшлекне үстерерү мөмкин булган өлкәләре: торак фондына техник хезмәт күрсәтү һәм аларны карап тоту, аерым алганда, йорт эчендәге системаларга хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау (сантехник, электротехник, җылылык системасы); торгызу-төзелеш эшләре; йорт яны территориясен карап тору; каты көнкүреш калдыкларын чыгару; торак фонды белән идарә итү; салкын су һәм кайнар суны исәпкә алу җайланмалары кую; территорияне яшелләндерү. Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә конкуренция үсешенең проблемалары булып, коммуналь инфраструктураның техник яраксыз хәлгә килүе югары дәрәҗәдә булу, куәтләрнең файдалы гамәлләре түбән коэффициентта һәм энергия чыганакларының зур чыгымнар таләп итүе тора.

Максат: торак-коммуналь хуҗалык үсеше буенча чаралар комплексын гамәлгә кую. Бурыч: торак-коммуналь хуҗалыгы базарында көндәшлекне үстерү өчен шартлар булдыру, күрсәтелгән икътисад факторларында көндәшлекне үстерүгә ярдәм итүче энергетик нәтиҗәлелекне модернизацияләү һәм стимуллаштыру.

Чаралар:

| № | Үткәрелүче чаралар исеме | Чараны уздыручылар һәм катнашучылар | Гамәлгә кую вакыты | Максатчан күрсәткечләр |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Концессион килешүләр нигезендә торак-коммуналь хуҗалык объектларын идарә итүне нәтиҗәсез гамәлгә ашыручы барлык дәүләт һәм муниципаль предприятиеләрне хосусый операторларга тапшыру | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты<br><br>төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы бүлеге | 2018-2020 еллар | ТХКобъектларын концессион килешүләр нигезендә тапшыру:<br>2018 елда –1 данә<br>2019 елда -1 данә<br>2020 елда -1 данә |

## 2.4. Пассажирлар йөртү өчен җир өсте транспорты өлкәсендәге хезмәт базары

Нурлат муниципаль районында пассажирлар йөртү буенча эшчәнлекне “Нурлат АТП”сы ААҖ алып бара. Хәрәкәт 13 транспорт чарасы белән 3 юнәлештә шәһәр буенча, 3 шәһәр яны юнәлешендә, 3 районара маршрут буенча башкарыла.

2017 ел дәвамында 23 меңгә якын пассажирга хезмәт күрсәтелгән.

Районда шулай ук шәхси такси кебек хезмәт тә эшли. Соңгы елларда пассажирлар ташу буенча шәхси фирмалар саны да артты. Хәзерге вакытта 4 такси фирмасы теркәлгән – “Союз”, “Элита”, “Картатар”, “Престиж», «Нурлат». Ныклы көндәшлек өчен шартлар тудырыла.

Шулай итеп, транспортта пассажирлар ташу өлкәсендәге хезмәт базарында транспорт хезмәтенең көчле тупланышы күзәтелә.

Муниципаль районда транспорт хезмәте күрсәтү өлкәсендә көндәшлек үсешенә тәэсир итүче факторлар булып:

- пассажирлар йөртүнең персонификацияләнгән исәбе булмау;
- транспорт предприятиеләренең чыгымнарны бәяләүдә нәтиҗәле системасы юклыгы;
- норматив таләпләргә туры килми торган түбән дәрәҗәдәге юллар тора.

Транспорт өлкәсендә көндәшлекне үстерүгә ярдәм итүче юнәлешләр булып:

- предприятиеләр тарафыннан, конкуренциягә сәләтлелекне һәм хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга, чыгымнарын киметүгә юнәлдерелгән чараларның хезмәт күрсәтү сыйфатын күтәрү максатларында транспорт комплексы эшләп чыгару;
- сыйфатлы хезмәт күрсәтү;
- транспортта йөрүнең куркынычсызлык дәрәҗәсен арттыру, аны халыкара транспорт куркынычсызлыгы стандартлары таләпләренә туры китерү;
- электрон хезмәт күрсәтү: билетлар сатып алу, такси чакыру, маршрут буенча мәгълүмат алу (хәрәкәт итү тәртибе, юл йөрү бәясе);
- 2 торак пунктка илтүче каты өслекле юл салу.

Проблема: район территориясендщ даими көндәлек оештырылучы пассажирлар ташу хәрәкәтләренең чыгымлы булуы, транспорт предприятиеләрендә чыгымнарны бәяли торган нәтиҗәле системаның юклыгы.

Максат: даими транспорт ташуда халыкның ихтыяҗларын канәгатьләндерү.

Бурыч: даими маршрутлар буенча пассажирлар ташуда көндәшлекне үстерү.

Чаралар:

| № | Үткәрелүче чаралар исеме | Чараны уздыручылар һәм катнашучылар | Гамәлгә кую вакыты | Максатчан күрсәткечләр |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Пассажирлар ташу өлкәсендә район эчендә һәм районара юнәлешләрдә көндәшлекне үстерү. | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы бүлеге | 2018-2020 еллар | Район эчендә һәм районара яңа маршрутлар ачу:<br>2018 елда –1 данә<br>2019 елда -1 данә<br>2020 елда -1 данә |

## 2.5. Ваклап сату базары

Халыкның тормыш дәрәҗәсен үстерү - 2016-2021 елларга һәм план рәвешендә 2030 елга кадәр Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы иҗтимагый-икътисадый үсешенең төп стратегияле максаты булып тора.

Ваклап сату базары - район күләмендә иң әһәмиятле һәм иң уңышлы үсеш алган, халыкны товар һәм хезмәтләр белән югары дәрәҗәдә тәэмин итүче өлкәләрнең берсе.

Сәүдә өлкәсе – районда һәрдаим үсештә булган өлкәләрнең берсе, ул 600 дән артык юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны берләштерә. Бу тармакта эре сәүдә челтәрләре дә, шулай ук ваклап сату предприятиеләре дә эшләп килә.

Кече һәм урта эшмәкәрлекнең 50% ка якыны сәүдә белән шөгыльләнә.

2017 ел нәтиҗәләре буенча ваклап сату өлкәсендә товар әйләнеше 8,9 млрд. сумны тәшкил итеп, узган ел белән чагыштырганда 101,4% ка җитте.

Соңгы елларда район кулланучылар базарында “Магнит”, “Пятерочка”, “Эссен”, “Светофор”, “Чаллы бройлер”, “Меценат” һәм башкалар кебек сәүдә кибетләр челтәре барлыкка килде.

Эре челтәрле сәүдә предприятиеләренең үсеше ваклап сату базары торышына, сатып алучыларның үсеп торучы ихтыяҗын канәгатьләндерүгә, халыкка хезмәт күрсәтү культурасы дәрәҗәсенә уңай йогынты ясый. Нурлат муниципаль районы ваклап сату базарында челтәрле сәүдә оешмалары килү белән көндәшлек үсеше дәрәҗәсе шактый артты.

Халыкның чын керемнәре түбәнәюе ваклап сату үсешенә дә тәэсир итте. Район халкы хәзер күбрәк промоакцияләргә игътибар итә, “кыйммәтле” азык-төлек алу азайды (ит урынына – ярымфабрикатлар, тавык ите хисабына эре терлек итеннән баш тарту, балык һәм диңгез продуктларын кулланмау).

Бу исә реаль чагылышта кайбер ваклап сату предприятиеләренең урта чегы, күп кенә район сәүдә нокталарында ваклап сату әйләнешенең кимүенә китерде.

Районда ваклап сату товар әйләнеше арттыру максатыннан, гади стационар сәүдә булмаган авыл җирлегендәге торак пунктларга күчмә сәүдә оештырылды.

Нурлат муниципаль районында ел саен авыл хуҗалыгы ярминкәләре уздырыла, монда үзләре җитештергән авыл хуҗалыгы продукциясен сатып алырга мөмкин. 2017 елның башыннан 15 ярминкә үткәрелде, 12,5 млн. сумлык азык-төлек сатылды.

Районда бәйрәм чаралары вакытында оештырылган сәүдә итү дә ваклап сату буенча товар әйләнешен арттыруга булышлык итә. 2017 елда әлеге чаралар вакытында сатылган продукциянең күләме 8 млн. сум тәшкил итте.

Ваклап сату базары үсешен тоткарлаучы каршылыклар булып:

- агымдагы финанслау һәм инвестицион эшчәнлек өчен үз ресурслар җитешмәве;
- кулланучылар активлыгы кимү;
- халыкның керем дәрәҗәсе түбәнәю;
- халыкның кредитлары күп булу;
- бәяләр арту санала.

Максат: кече эшмәкәрлек белән шөгыльләнүчеләргә көндәшлеккә сәләтлелекне үстерүгә һәм җитештерелгән продукцияне урнаштырганда булышлык итү өчен мәгълүмат һәм оештыру системасын булдыру.

Бурычлар:

- ваклап сату өлкәсендә намуслы көндәшлелек үсеше;
- авыл хуҗалыгы продукциясе (чимал) һәм эшкәртелгән продукциянең бәяләрен мониторинглау;
- авыл хуҗалыгында җитештерелгән продукцияне сату өчен агросәнәгать базарлары ачу.

Чаралар:

| № | Үткәрелүче чаралар исеме | Чараны уздыручылар һәм катнашучылар | Гамәлгә кую вакыты | Максатчан күрсәткечләр |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан яңа сәүдә объектлары ачылу | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты,<br><br>территориаль үсеш бүлеге | 2018-2020 еллар | Яңа сәүдә объектлары ачу:<br><br>2018 елда –2 данә<br><br>2019 елда -2 данә<br><br>2020 елда -2 данә |
| 2. | Ярминкәләр уздыру, базарлар һәм ярминкәләрдә ваклап сату мөмкинлеген тәэмин итү | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты,<br><br>территориаль үсеш бүлеге, авыл хуҗалыгы бүлеге | 2018-2020 еллар | Яңа сәүдә объектлары ачу:<br><br>2018 елда –7 данә<br><br>2019 елда -9 данә<br><br>2020 елда-11 данә |
| 3. | Ярминкәләрдә авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре тарафыннан җитештерелгән үз продукцияләрен сатуны арттыру, шулай ук гражданнарның сатыла торган продукциягә бәяләр билгеләү буенча ихтыяҗларын тәэмин итү буенча чараларны гамәлгә ашыру. | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты,<br><br>территориаль үсеш бүлеге, авыл хуҗалыгы бүлеге | 2018-2020 еллар | Узган ел белән чагыштырганда, авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең ярминкәләрдә үз продукцияләрен сату күләменең үсеше, %:<br>2018 елда –103,0;<br>2019 елда -105,0;<br><br>2020 елда -106,0. |
| 4. | Район кибетләр челтәрендә җирле товарлар сатуның күләмен арттыру буенча чараларны гамәлгә ашыру | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты,<br>территориаль үсеш бүлеге | 2018-2020 еллар | Кибетләр челтәрендә җирле товар әйләнешенең күләме арту<br>2018 елда –102%;<br>2019 елда -103%;<br><br>2020 елда -104%. |

## 2.6. Ит, ит продуктлары һәм авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү базары

Нурлат муниципаль районы икътисады авыл хуҗалыгы белән тыгыз бәйләнгән. Күпчелек халыкның яшәү дәрәҗәсе аның үсешеннән гыйбарәт. Район халкының 43% авыл җирлегендә гомер итә. Эшләүче кешеләрнең зур өлеше авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә, крестьян – фермер хуҗалыкларында һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларда хезмәт куя.

Район авыл хуҗалыгының җитештерү буенча юнәлеше – терлекчелек белән алга киткән игенчелек.

Сөрү җирләренең күләме соңгы 5 ел эчендә өч мәртәбә артты, район күләмендә ул 87282 га тәшкил итә.

Нурлат муниципаль районы территориясендә ит һәм ит продуктлары җитештерү белән 50 дән артык авыл хуҗалыгы җитештерүчесе шөгыльләнә.

Ит ризыклары районда иң кирәкле азык-төлекнең берсе булып тора. Азык-төлек арасында  ит базары бөртек һәм сөт базарларыннан узып иң эреләрдән санала. Мондый төр базарның аерым роль уйнавы әлеге төркем азык-төлекне җитештерү һәм куллануның җитәрлек дәрәҗәдә зур күләме әһәмияте белән генә түгел, ә кешенең туклану рационында балык һәм сөт продуктлары белән беррәттән төп аксым чыганагы буларак та билгеләнә. Хәзерге вакытта, Россия Федерациясе хөкүмәте тарафынан куелган илнең азык-төлек иминлеге  һәм чит ил товарларын үзебезнекеләргә алыштыру бурычлары беренче чиратта итеп билгеләнгәч, әлеге базарны үстерүгә зур игътибар бирелә. Эре, урта һәм кече эшмәкәрлекнең бары тигез дәрәҗәдә ярашуы авыл хуҗалыгы җитештерүчәнлегенең тотрыклы үсешен, авыл халкының тормыш дәрәҗәсе артуын тәэмин итәргә сәләтле.

Ит, ит продуктлары һәм авыл хуҗалыгында кош-корт җитештерү хезмәте базары -  шактый катлаулы һәм бер үк вакытта сату, азык кайгырту һәм күпләп сату бәяләрен хәл итүне сорый торган өлкә.

Савым көтүен яңарту, мөгезле эре терлек санын, бигрәк тә  яшь терлекләрне саклау  - терлекләрнең баш саны  күрсәткече -  төп мәсьәлә булды һәм шулай булып кала бирә.

Район  күләмендә авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә һәм крестьян-фермер хуҗалыкларында 2018 елның 1 гыйнварына 19,5 мең баш тәшкил итте, шул исәптән сыерлар – 7,5 мең, сарыклар һәм кәҗәләр – 1.9 мең. Кош-кортның баш саны бер меңгә якын.

2017 елда районда 2349 тонна ит җитештерелгән, узган ел белән чагыштырганда 15% ка күбрәк.

Ит, ит продуктлары һәм авыл хуҗалыгында кош-корт җитештерү хезмәте базарында көндәшлекне үстерүгә комачаулый торган сәбәпләр булып:

- кече эшмәкәрлек төрләренең җитештерүне оештыру һәм беренчел эшкәртү өлкәләрендә начар үсеше;

- авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең финанс ягыннан какшап торуы, авыл хуҗалыгы оешмаларының инвестиция ягыннан түбән җәлеп итүчәнлеге;

- кредит ресурсларының авыр булуы һәм залог белән тәэмин ителешнең кимчелекле булуы;

- республика бюджетыннан авыл хуҗалыгы үсешенә ярдәм йөзеннән бүлеп бирелә торган өлешнең чикләнгән күләмдә булуы;

- төп җитештерү фондларын аларны бастыру белән чагыштырганда алдан кыскарту, авыл хуҗалыгы техникасы паркының төп төрләрен кыскарту һәм таушалу, үсемлекчелектә һәм игенчелектә заманча технологияләр кертүнең түбән темплары;

- вакыйгалар үзен аклау өчен озак вакыт таләп ителгән очракта, башлангыч зур акчалар куюю кирәклеген гамәлгә ашыру;

- хуҗалык итүче субъектларда җитәрлек күләмдә саклау урыннары, складлар, авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел эшкәртү өчен пунктлар булмау;

- күмәртәләп сатып алу инфраструктурасының җитәрлек дәрәҗәдә үсеш алмавы;

- авыл җирлекләрендә тормыш шартларының җәлеп итмәслек булуы, авыл халкының тормыш дәрәҗәсе югары булмавы, иҗтимагый инфраструктураның (сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният) хезмәт күрсәтү сыйфаты җитәрлек дәрәҗәдә булмавы, балалар туу кимү яшьләрнең китүе тора.

Ит җитештерү, ит продуктлары һәм авыл хуҗалыгында кош-корт базарында катнашучыларның санын тиешле дәрәҗәдә булдыру максатында, алар арасында көндәшлекне үстерү, аларның җитештерү нәтиҗәлелеген күтәрер өчен агросәнәгать комплексы гамәлдәге ярдәм программалары кысаларында чаралар комплексын гамәлгә ашыруны дәвам итү мөһим.

Өстәмә рәвештә, шул исәптән, базарларда һәм ярминкәләрдә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең продукциясен сату базарларын киңәйтү буенча чараларны тормышка ашыру кирәк.

Кече һәм урта эшмәкәрлекнең алга таба үсеше авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек продукциясе җитештерүчеләре арасында нәтиҗәле көндәшлек үсешенә ярдәм итәчәк, эшмәкәрлектә чыгымнарны кыскартуга китерәчәк һәм инновацияләр өчен юлны ачачак.

Кече һәм урта эшмәкәрлекнең инфраструктура, финанслар, табигый ресурслар, муниципаль сатып алулар һәм башка мәгълүмат базасына керү процедурасында ачыклыгын тәэмин итү, кече һәм урта бизнеста көндәшлеккә сәләтлелекне сыйфатлы итеп күтәрергә сәләтле буларак, тулаем алганда, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренең дә көндәшлеген күтәрергә сәләтле.

Ит һәм ит продуктлары базарын тулыландыруның тагын бер мөһим чыганагы булып азык базасын ныгыту, көтүнең генетик потенциалын камилләштерү тора.

Районда ит, ит продуктлары һәм авыл хуҗалыгында кош-корт җитештерү буенча хезмәтләр күрсәтү базарын үстерү максаты булып җирле җитештерелгән продукция өлешен арттыру санала.

Бурыч: терлекчелек һәм кошчылык өлкәсендә хуҗалыкның кече төрләрен үстерү (крестьян (фермерлык) хуҗалыгы, шәхси ярдәмче хуҗалыклар, гаилә фермалары).

Чаралар:

| № | Үткәрелүче чаралар исеме | Чараны уздыручылар һәм катнашучылар | Гамәлгә кую вакыты | Максатчан күрсәткечләр |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Ит, ит продуктлары җитештерү һәм авыл хуҗалыгында кош-корт үрчетү өлкәсендә кече эшмәкәрлек формасын үстерү | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты,<br><br>авыл хуҗалыгы бүлеге | 2018-2020 еллар | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан ит, ит продуктлары җитештерү һәм авыл хуҗалыгында кош-корт үрчетүне үстерү, киләсе ел белән чагыштыргында, %<br>2018 елда –5;<br><br>2019 елда -5,5;<br>2020 елда -6. |
| 2. | Ит, ит продуктлары җитештерү һәм авыл хуҗалыгында кош-корт үрчетү буенча районда эшләп килүче комплексларны камилләштерү һәм яңаларын ачу | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты,<br><br>авыл хуҗалыгы бүлеге | 2018-2020 еллар | Ит, ит продуктлары җитештерү һәм авыл хуҗалыгында кош-корт үрчетү буенча районда эшләп килүче комплексларны камилләштерү һәм яңаларын төзү, данә:<br>2018 елда –1;<br>2019 елда -1;<br>2020 елда -2. |

## 2.7. Мәдәният өлкәсендә хезмәт базары

Нурлат муниципаль районы мәдәни тормышы бай һәм киңкырлы. Иҗтимагый тормышта мәдәният - бәйләүче буын, ул барлык милләтләрнең бердәмлек һәм татулык чыганагы булды һәм булып кала бирә.

Нурлат муниципаль районында 100 бүлекчәдән торучы 3 муниципаль мәдәният учреждениесе челтәре эшләп килә.

Узган ел дәвамында мәдәният учреждениеләре тарафыннан 10 меңнән артык төрле чаралар үткәрелде: күргәзмә, концертлар, әдәби укулар, ачык һавада массакүләм чаралар һ.б.

Мәдәният өлкәсендә көндәшлек җитәрлек дәрәҗәдә үсеш алмаган.

Мәдәният өлкәсендә хезмәт базарында каршылыклар бар әле:

- мәдәният өлкәсендәге учреждениеләрнең гомуми санында дәүләтнеке булмаган оешмаларның өлеше түбән булу;
- мәдәният учреждениеләре тарафынан күрсәтелә торган хезмәтләрнең гражданнарның теләк –өметләренә, ихтыяҗларына җавап бирер дәрәҗәдә тулы булмаган туры күләмдә һәм төрдә булуы;
- концерт-театр оешмаларының хезмәт күрсәтү буенча проектлары, хәтта минималь табыш алганда да, югары финанс куркынычлылыгы булган проектларга каравы.

Максат: мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә конкуренция үсеше өчен шартлар тудыру, сәнгатьтә төрле юнәлешләр буенча мәдәни продукт төрлелеген күтәрү (мәгариф, музыка, театр, хореография сәнгате, кино һ. б.).

Бурыч: Театраль тамаша оешмалары үткәрүче чараларның гомуми күләмендә коммерцияле оешмалар тарафыннан уздырылучы чаралар өлешен арттыру.

Чаралар:

| № | Үткәрелүче чаралар исеме | Чараны уздыручылар һәм катнашучылар | Гамәлгә кую вакыты | Максатчан күрсәткечләр |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә конкуренция үсеше өчен шартлар тудыру | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты<br><br>-“Мәдәният үсеше үзәге”МБУ;<br>-“Нурлат балалар сәнгать мәктәбе” өстәмә белем МБУ;<br>-“Җирлекара үзәк китапханә” МБУ. | 2018-2020 еллар | Районда театраль тамаша оешмалары үткәрүче чараларның гомуми күләмендә коммерцияле оешмалар тарафыннан уздырылучы чаралар өлеше, %<br>2018 елда –1,2;<br><br>2019 елда -1,24;<br>2020 елда -1.33. |

## 2.8. Туризм өлкәсендә хезмәт базары

Район мәдәният учреждениеләре эшчәнлегендә төп юнәлешләренең берсе булып Нурлат муниципаль районы мәдәни мирасын саклап калу һәм популярлаштыру, мәдәни хезмәт күрсәтүнең сыйфатын күтәрү, район халкының иҗади потенциалы үсешен тормышка ашыру, халык рухын арттыру, эчке туризмның тотрыклы үсеше өчен шартлар тудыру тора.

Нурлат муниципаль районы территориясендә республика буйсынуындагы мәдәни мирас һәйкәлләре - 7объект бар, шулай ук археологик һәйкәлләр, табигать архитектурасы, тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр.

Районда туризм өлкәсендә хезмәт базары үсешен тоткарлаучы сәбәпләр булып:
- тарихи мирасны өйрәнү буенча үсеш алган маршрут булмау;
- бина торышы канәгатьләнерлек булмау сәбәпле, булган мәдәни мирас объектларына ихтыяҗ тумау;

- Нурлат муниципаль районы сайтында урнаштырылган интерактив электрон туристик карта юклыгы;
- алдан уйланылган маршрут кысаларында, туризм өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыруда авыл җирлекләрен җәлеп итмәү;
- мәдәни мирас объектларын төзекләндерүдә финанслар бүленмәү.

Максат: туризмны үстерү.

Бурыч: туризм өлкәсендә хезмәт базарын үстерү.

Чаралар:

| № | Үткәрелүче чаралар исеме | Чараны уздыручылар һәм катнашучылар | Гамәлгә кую вакыты | Максатчан күрсәткечләр |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Туризм үсеше, туристлык маршрутлары булдыру | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты,<br><br>Кама арьягы һәм Нурлат шәһәре тарихы төбәк музее;<br>Г. Кариев исемендәге Колбай-Мораса тарих музее | 2018-2020 еллар | Узган ел белән чагыштырганда туристлык агымының үсеше, %<br>2018 елда –7;<br><br>2019 елда -12;<br>2020 елда -15. |

## 3. Көндәшлекне үстерү өлкәсендә беренчел чаралар

Секторлы товар базарларында конкуренция үстерү чаралары югарыда күрсәтелде. Шулай да көндәшлекне үстерүгә комачаулый торган төп каршылыклар да бар. Аларга административ һәм икътисадый каршылыкны кертергә мөмкин.

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү тәртибен саклау максатыннан, вакытында үтәү һәм хезмәтләрнең ачыклыгына таянып районда дәүләт хезмәтләре күрсәтү регламентлары эшләнелгән һәм Нурлат муниципаль районы рәсми сайтына ирекле хөкемдә урнаштырылган.

Нурлат муниципаль районында хезмәт тәкъдим итүчеләрне сайлап алу вәкаләте белән (подрядчылар, башкаручылар) Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты билгеләнгән. 44-ФЗ номерлы Федераль законның 38 маддәсе нигезендә контракт хезмәте булдырылды, әлеге бүлеккә җитәкче урынбасарлары һәм бүлек башлыклары керә. 44-ФЗ номерлы Федераль законның 39 маддәсе нигезендә 7 кешедән торучы сатып алулар буенча бердәм комиссия төзелде. Аның составына Башкарма комитет җитәкчесенең урынбасары һәм 6 бүлек башлыгы керә, елга бер-ике тапкыр комиссия әгъзаларының урыннары алышына. Вәкаләтле оешма тарафынан 109 муниципаль бюджет учреждениесенә көндәшлелек тәртибе нигезендә сатып алулар уздырыла, шулар арасында 69 белем бирү оешмасы, 26 авыл җирлеге, 14 башка төр бюджет учреждениесе бар. Татарстан

Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетына муниципаль заказларны урнаштыру вазыйфасы йөкләнгән.

Районда муниципаль контрактларның саны һәм күләменең даими үсеше күзәтелә.

2017 елда 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон кысаларында Нурлат муниципаль районы урнаштырган муниципаль заказларның күләме 200 751 798 сум тәшкил итте.

2017 елда кече эшмәкәрлек субъектлары өчен уздырылган муниципаль сатып алуларның өлеше 30% тан артык.

Сатып алу эшчәнлегендә камилләштерү һәм ачыклыкны арттыру буенча эш алып барыла. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 ел, 31 декабрь, 1087 нче карары белән (үзгәрешләр кертелгән карар 2017 елның 5 апрелендә) Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен сатып алулар планын раслау һәм алып бару турында (алга таба –Тәртип) расланды. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль органнары һәм учреждениеләре эш регламентын һәм бердәм кагыйдәләрен планлаштыру һәм сатып алуны нигезләгәндә җайга салу максатларында эшләнде. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен хезмәт күрсәтүләр, товарлар, эшләр планнарына үзгәрешләр керткәндә һәм формалаштырганда, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль органнарының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи затлары, муниципаль казна учреждениеләре, муниципаль бюджет учреждениеләре һәм муниципаль автоном учреждениеләре эш тәртибе кагыйдәләрен билгели.

100/400 меңгә кадәр булган муниципаль заказлар «Биржа мәйданчыгы» электрон сәүдә мәйданында башкарыла.Әлеге мәйданчыкта муниципаль һәм дәүләт заказчылары зур күләмдә азык-төлек сатып ала ала, бу сатып алуларны тагын да ачык итә. Әлеге электрон мәйданчык аша товарлар сатып алуның уңай ягы булып сатып алу тәртибенең 2 көн эчендә башкарылуын, заказчылар эшенең күпкә җиңеләйтелүен атарга кирәк. Моңа өстәп, товар җитештерүчеләр төп катнашучылар: фермерлар, сыйфатлы товар җитештерүче шәхси эшмәкәрләр.

Районның 55 балалар бакчасы “Биржа мәйданчыгы” аша азык-төлек сатып ала.

Сатып алуларны оештыру белән шөгыльләнүче хезмәткәрләрнең белемнәрен күтәрүгә дә зур игътибар бирелә. Нурлат муниципаль районында берничә тапкыр сатып алулар белән бәйле муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре өчен 44-ФЗ номерлы “Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы” Федераль законы нигезендә үзәкләштерелгән укулар уздырылды. 2017 елда 76 хезмәткәр белемен күтәрү турында таныклык алды. Хәзерге вакытта барлык хезмәткәрләр дә әлеге таныкклыкка ия, һәрбер оешмада 44-ФЗ номерлы Федераль законның 38 маддәсе нигезендә контракт идарәчесе билгеләнгән (Контракт хезмәте).

Хезмәт тәкъдим итүчеләрне сайлап алу вәкаләте йөкләнгән Вәкаләтле оешма хезмәткәрләре тарафыннан, муниципаль заказ урнаштыру эшчәнлегенен оештыруны камилләштерү максатларында, муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен

товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә законнар үзгәреше даими өйрәнелә һәм күзәтеп барыла.

Дәүләт һәм муниципаль сатып алулар системасында киләчәктә көндәшлекне үстерүне дәвам итәр өчен ришвәтчелек факторлары йогынтысын киметергә мөмкинлек бирүче электрон сәүдә системасын үстерергә һәм сатып алуларны тагы да ачык рәвешле итәргә планлаштырыла.

Шулай ук Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында буш торучы мәйданчыклар турында мәгълүмат урнаштырылган. Бу, үз чиратында, район базарларында җитештерүчәнлекне үстерер өчен инвесторларга ачык тәкъдим – чакыру. Төп максат – көндәшлекне үстерү.

## 4. Программаны гамәлгә ашыру тәртибе

Программа Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана. Программаны гамәлгә ашыру чаралары планы нигезендә, җаваплы хезмәткәрләр, киләсе айның 10 кадәр үткәрелгән чаралар турында Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты территориаль үсеш бүлегенә нәтиҗәләр турында хисап җибәрә.

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты территориаль үсеш бүлеге мәгълүматны анализлап гомумиләштергәннән соң югарырак оешмаларга мәгълүмат юллый.

Программада каралган чараларның эчтәлеге программа чаралары һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү турындагы хисап нигезендә төгәенләнергә мөмкин.

Программа чараларын гамәлгә куюны контрольдә тоту Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләнелә.